РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИТРЯЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЕТРӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

---

«19» апрель 2024 ел Метрәй авылы № 7

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге территориясендә кыргый наркотиклы үсемлекләр үсү урыннарын ачыклау һәм юк итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Башкарма комитетының «02» февраль 2024 елдагы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге территориясендә кыргый наркотиклы үсемлекләрнең үсү чыганакларын ачыклау һәм юкка чыгару чаралары турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «02»февраль 2024 елгы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм 1 нче кушымта нигезендә наркотик булган үсемлекләрне ачыклау һәм бетерү буенча эшче төркем составын бәян итәргә.
2. 4 бүлекнең 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Эшче төркем утырышлары елына кимендә ике тапкыр уздырыла, июнь-сентябрь айларында.».

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Метрәй авыл җирлеге
Башкарма комитет Җитәкчесе Г.И.Шакирова

Метрәй авыл җирлеге җитәкчесенең
«19»апрель 2024 ел 7 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге территориясендә кыргый, наркотиклы үсемлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча эшче төркем составы**

**Эшче төркем рәисе:**

Шамгунов Ильдус Вахит улы - авыл җирлеге Башлыгы:

**Эш төркеме сәркатибе:**

Шакирова Гюзелия Ислам кызы - авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе

**Эшче төркем әгъзалары:**

Мингазова Сирена Саит кызы - Салауз-Мухан авылы фельдшеры (килешү буенча);

Шайгарданова Илюза Фаяз кызы- Метрәй мәдәният йорты режиссеры (килешү буенча).